**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2023 елның 31 октябре 3449 номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 26 мартындагы 571 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге территориясен тотрыклы үстерү, әйләнә-тирә мохитне саклау өчен шартлар тудыру, физик һәм юридик затларның территорияләрен планлаштыру, физик һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү өчен шартлар тудыру, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясындагы 1 пункты 30, 31, 32 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 26 мартындагы 571 номерлы карарына.

2. 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә;

4. Әлеге карарны «Кама ягы» («Камская новь») район газетасында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында: http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А.П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Башкарма комитетының
202__ елның _____ номерлы
карарына 1 кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү комиссиясе составы**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Шитов И. П. | Инфраструктур үсеш буенча Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе; |
| 2. | Карсалов А. П. | Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы, Комиссия рәисе урынбасары; |
| 3. | Кондратьева А.А. | Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге баш белгече, комиссия секретаре; |
| | **Комссия әгъзалары**: | |
| 4. | Шәрәфиев И.Г. | Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге Советы рәисе ; |
| 5. | Җамалиев Л.М. | Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади һәм инвестицион үсеш буенча урынбасары; |
| 6. | Хисматова Э.В. | Лаеш муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе; |
| 7. | Зотин Р.Ю. | Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм торак фондын исәпкә алу бүлеге башлыгы;; |
| 8. | Маков А.И | Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча); |
| 9. | Федорина Е.П. | Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлегенең баш белгече; |
| 12. | ШиҺабиев И.Ш. | Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенең Лаеш бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| 13. | Гиниятуллин И.К. | «Техник инвентаризация бюросы» АҖнең Лаеш бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча). |